КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 июнь г.Казань № 493

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 12 июль, 565 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына, Кодификаторның «Дүртенче» графасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «01.07.04.3 | Пространство белешмәләре белән идарә итү». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы һәм 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«пространство белешмәләре белән идарә итү (01.07.04.3*).»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән үзара бәйләнештә була:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салу (01.10*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

энергия һәм ресурлар саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү (01.02.1*);

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

торак базарларын; торак-коммуналь хезмәтләр формалаштыру өчен шартлар тудыру (04.01.01*);

федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән берлектә территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документлары проектларын әзерләүне оештыру (01.05.01.02*);

билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләрнең чикләрен билгеләү белән идарә итү (01.05.01.03*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01.03*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә итүдән тыш) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (02.04.01*);

норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03*);

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән – архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03*).».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы, 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче; 2018 ел, 4 июль, 545 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2019 ел, 16 апрель, 301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән үзара бәйләнештә була:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

озак вакытлы этапка социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.1*);

макроикътисадый программалаштыру (01.01.1.1*);

озак вакытлы этапка төбәк программалаштыруы (01.01.1.2*);

озак вакытлы этапка тармак программалаштыруы (01.01.1.3*);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.2*);

планлаштырыла торган елга гомуми икътисадый программалаштыру (01.01.2.1*);

планлаштырыла торган елга төбәк программалаштыруы (01.01.2.2*);

планлаштырыла торган елга тармак программалаштыруы (01.01.2.3*);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10*);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11*);

дәүләт учреждениеләренең фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлеге белән идарә итү (Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү учреждениеләреннән һәм алар төзегән фәнни оешмалардан тыш) (01.12.02*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасының ведомстволарга караган дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2*);

Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

энергия һәм ресурлар саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

электр энергетикасы белән идарә итү (03.01.01*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә итүдән тыш) функциясен гамәлгә ашырганда)  (01.15.02*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү (01.02.1*);

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

билгеләнгән тәртиптә хезмәт белән идарә итү 01.13*);

хезмәт өчен түләүне, хезмәт мөнәсәбәтләрен, турыдан-туры хезмәткә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.13.01*);

хезмәтне саклау белән идарә итү (01.13.02*);

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм өлкәсендә эшчәнлекне җайга салу һәм оештыру (01.13.03*);

инвалидларның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү белән идарә итү (04.06.04*);

халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү белән идарә итү (04.06.06*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә итү (02.01.02*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (02.01.03*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – өстәмә һөнәри белем бирү белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү, федераль мәгариф оешмаларында алына торган белемнән тыш) функциясен гамәлгә ашырганда (04.05.08*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итү (01.07*);

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорттан, җиһазлардан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү (01.07.01*);

территорияне планлаштыру (01.05.01*);

территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләүне тәэмин итү (01.05.02*);

шәһәр төзелешен проектлауның төбәк нормативларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.03*);

пространство белешмәләре белән идарә итү (01.07.04.3*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

билгеләнгән тәртиптә табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләти җайга салуда һәм тикшереп торуда катнашу (01.09.01*);

билгеләнгән тәртиптә торак-коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләрне (тарифларны) җайга салу (01.09.02.1*);

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе белән – капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән өченче һәм дүртенче класслы гидротехник корылмаларны төзегәндә, реконструкцияләгәндә төбәк дәүләт төзелешен күзәтчелеге функциясен гамәлгә ашырганда (01.05.06*);

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе белән – халыкка торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүне билгеләнгән тәртиптә тикшерүдә тоту функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.01.04*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигать ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин